**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3835**
**26.07.2019**

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкендәге мөлкәтне исәптән чыгару тәртибе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган беренчел исәп документлары һәм бухгалтер исәбе регистрлары формаларын һәм аларны куллану буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 52н санлы Приказы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 3.18, 5.24 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2009 елның 16 декабрендәге 5943 нче карары белән (Башкарма комитетның 2010 елның 21 декабрендәге 8327 нче, 2014 елның 15 гыйнварындагы 134 нче карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль милкендәге мөлкәтне исәптән чыгару тәртибе турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 пунктның өченче пунктчасында «(№ ОС-4, № ОС-4а, № ОС-4б формалары)» сүзләрен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы приказы белән расланган форма буенча (исәптән чыгарыла торган мөлкәт төренә бәйле рәвештә) рәсмиләштерелгән» сүзләренә алмаштырырга;

2) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Түбәндәге нигезләр буенча мөлкәтне исәптән чыгару кире кагыла:

1) исәптән чыгару турында гариза белән тиеш булмаган зат мөрәҗәгать итү;

2) мөлкәтне исәптән чыгару өчен бирелгән документлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, әлеге нигезнамәгә туры килмәү.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин